ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планын расларга (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2016 елның 26 октябре
№ 1423-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2016 елның 26 октябрендәге
1423-V ДС номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2017 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планы**

| № т/б | Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы тәкъдимнәре | Гамәлгә ашыру буенча чаралар | Башкару вакыты | Башкару өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга булышу граждан җәмгыятен үстерүгә ярдәм итә. Дәүләт функцияләрен, моңа халыкка социаль хезмәтләр күрсәтә алуны тәэмин итү дә керә, аларга тапшыру буенча кыюрак эш итәргә кирәк. Әлеге эштә төп урынны республиканың Иҗтимагый палатасы, ведомство һәм муниципаль иҗтимагый берлекләр алып тора. | 1.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары карамагындагы мәсьәләләр буенча социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар белән үзара эшчәнлек. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары рәисләре, Ю.З. Камалтынов, Х.Г. Миргалимов |
| 2. | Республиканың иҗтимагый тормышында ватанпәрвәрлекнең әһәмияте арта бара. Агымдагы елның 9 маенда 170 мең татарстанлы “Үлемсез полк” акциясендә катнашты. Бу – буыннар бәйләнешенең, ата-бабаларыбызга олы ихтирамның һәм югары әхлаклылыкның ачык чагылышы. Патриотик тәрбия бирүдә ДОСААФ, иҗади берлекләр һәм оешмалар, шулай ук мәктәп укучыларының һәм яшь армиячеләрнең иҗтимагый хәрәкәтләре | 2.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең “Үлемсез полк” акциясендә, патриотик юнәлешле башка чараларда катнашулары.<br><br>2.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе әгъзаларының кайбер мәгариф | 2017 елның мае, ел дәвамында<br><br>2017 елның мае | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты<br><br>Х.Г. Миргалимов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | мөмкинлекләрен активрак җәлеп итәргә кирәк. | оешмаларында “Җиңү Байрагы” дәресен үткәрүе. | | |
| 3. | Татарстандагы һәр гаилә хакимият органнарының, иҗтимагый оешмаларның, массакүләм мәгълүмат чараларының һәрвакыт игътибар үзәгендә булырга һәм аларның ярдәмен тоеп яшәргә тиеш. Авыр тормыш хәлендә калган гаиләләр турында онытырга ярамый. Лениногорск районындагы коточкыч хәлне барыбыз да хәтерлибез. Мондый хәл башка кабатланырга тиеш түгел! | 3.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетында “2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге · гамәлләрнең республика стратегиясен гамәлгә ашыру турында” мәсьәләне карау. | 2017 елның мае | С.М. Захарова |
| 4. | Милләтара һәм конфессияара тынычлык һәм татулык безнең башкалардан иң нык чагылыш таба торган өстенлегебез булып кала бирә. Дөньядагы тискәре тенденцияләр һәм өндәүләр, шулай ук аларга бәйле хәлләр фонында бу аеруча зур кыйммәткә ия. Агымдагы елда бай тарихи-мәдәни мирасыбызны торгызу һәм үзебездә дини белем бирүне камилләштерү өлкәсендә беренче җитди адымнар ясалды.<br>Болгар ислам академиясен төзү һәм Казан Мәрьям Ана иконасы соборын яңадан торгызу кебек әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыру башланды. Мондый проектлар, Борынгы Болгар һәм Зөя утрау-шәһәрен яңадан торгызу белән беррәттән, республикабыздагы төп конфессияләр арасында тигезлекне һәм үзара ихтирамны чагылдыра, аларның алга таба да үзара эшчәнлегенә ныклы нигез сала. | 4.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты депутатларының дини темалар буенча республикада уздырыла торган чараларда катнашулары. | 2017 ел дәвамында | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Шунысы мөһим, әлеге башлангычларда без федераль хакимият органнары, мөселман һәм православие җәмәгатьчелеге лидерлары, бизнес һәм республикабызның барлык халкы тарафыннан хуплау һәм аңлау табабыз.<br>Мәскәүнең һәм бөтен Русьнең Изге Патриархы Кириллның Татарстанга килүе рухи кыйммәтләрне һәм диннәр арасындагы үзара багланышларны үстерүдә Татарстанның зур роль уйнавын саллы тану булды, ул торгызыла торган Казан Мәрьям Ана иконасы соборының нигезенә истәлек ташын салу тантанасын җитәкләде.<br>"Изге Болгар җыены", Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы, шулай ук Болгар ислам академиясенә нигез салуга багышланган тантаналар аеруча зурлап уздырылды. Әлеге академия киләсе елда ачылыр дип көтелә. Академия мөселман дини белем бирү системасының иң югары баскычы, татар дини белем бирү мәктәбе традицияләрен саклауның нигезе һәм Россия татар-мөселман җәмәгатьчелеген берләштерүче булырга тиеш. | | | |
| 5. | Җәмгыятьтә технологияләрнең тиз үсүе, каршылыклы процесслар мәгълүмат киңлегендә зур үзгәрешләргә китерә. Басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары белән беррәттән, социаль челтәрләр дә торган саен зуррак роль уйный. Яңалыкларны халыкка җиткерү инструменты буларак төрле | 5.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында "Татарстан-24" телеканалы концепциясе турында"гы мәсьәләне карау.<br><br>5.2. КПРФның Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы фракциясе | 2017 елның ноябре<br><br><br><br><br>2017 елның<br>II кварталы | Р.И. Вәлиев<br><br><br><br><br>Х.Г. Миргалимов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | мобиль кушымталар өстенлеккә ия була башлады. Бүген көнүзәк вакыйгаларга оператив рәвештә мөнәсәбәтеңне белдерү, бу хакта фикереңне, гамәлләреңне һәм карарларыңны халыкка җиткерү аеруча мөһим. Бу тулысынча хакимият органнарына һәм, барыннан да элек, "Татмедиа" агентлыгына кагыла. Республикабыздагы һәр кешенең, ул кайсы чыганакны сайлавына карамастан, төгәл мәгълүмат алу мөмкинлеге булырга тиеш. | утырышында мәгълүмат җиткерүнең яңа форматларын үзләштерү буенча "Татмедиа" агентлыгы эшчәнлеге турындагы мәсьәләне карау. | | |
| 6. | Татарстанның уңышлы үсешенә халык ярдәменнән һәм аның өлеш кертүеннән башка ирешү мөмкин түгел. Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары халык белән үзара эшчәнлекнең нәтиҗәле юлларын табарга, республиканың нәтиҗәле проектларын гамәлгә ашыруга киң җәмәгатьчелекне, шул исәптән территориаль иҗтимагый җирле үзидарәләрне актив җәлеп итәргә тиеш. | 6.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты утырышында "Татарстан Республикасында территориаль иҗтимагый җирле үзидарәләр эшчәнлеге турында" контроль мәсьәләне карау. | 2017 елның IV кварталы | А.Г. Хәбибуллин |
| 7. | Хакимият органнары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү эшен дәвам итү мөһим. Бу – коррупциячел күренешләрне киметүнең иң нәтиҗәле чарасы. | 7.1. 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының коррупциягә каршы программасы чараларын үтәү. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты |
| | | 7.2. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы яисә комитетлары тарафыннан кертелгән Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштыру эшен дәвам итү.<br><br>7.3. Дәүләт хезмәтләре порталында Татарстан Республикасында норматив хокукый актлар проектлары буенча иҗтимагый фикер алышулар сервисы эшенә ярдәм итү. | <br><br><br>ел дәвамында | <br><br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты |
| 8. | Уңайлы мохит тудыру буенча башланган эшнең дәвамы итеп, 2017 ел республикада Экология һәм җәмәгать киңлекләре елы дип игълан ителә.<br>Россиядә Экология елы булуын истә тотып, шәһәр һәм авылларыбызны яшелләндерүне, сулыкларны төзекләндерүне дәвам итәчәкбез... | 8.1. “Татарстан Республикасының муниципаль районнарында ярларны ныгыту эшләрен башкарганда “2012 – 2020 елларда Россия Федерациясе су хуҗалыгы комплексын үстерү” федераль максатчан программасы кысаларында бүлеп бирелгән бюджет акчаларын нәтиҗәле файдалану турында”гы контроль мәсьәләне карау.<br><br>8.2. Депутатлар һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең Татарстан Республикасында Экология һәм җәмәгать киңлекләре елы кысаларында уздырыла торган чараларда катнашулары.<br><br>8.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында “Татарстан Республикасында 2017 елны Экология һәм җәмәгать киңлекләре елы итеп игълан итүгә бәйле планлаштырылган чаралар турында” мәсьәләне карау. | 2016 елның IV кварталы<br><br><br><br><br><br><br><br><br>ел дәвамында<br><br><br><br><br><br><br>ел дәвамында | Л.А. Якунин<br><br><br><br><br><br><br><br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты<br><br><br>Т.Г. Һадиев |
| 9. | Республиканың халыкара элемтәләрне үстерүдә парламентара багланышлар | 9.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе | 2016 елның декабре, ел дәвамында | А.Г. Хәбибуллин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | мөһим роль уйный. Монда без үзебезнең депутатларыбызга таянабыз. Әлеге эшнең нәтиҗәсе Татарстанның сәяси имиджын күтәрүдә һәм икътисадый мәнфәгатьләребезне алга чыгаруда чагылырга тиеш. | субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең еллык планын раслау һәм гамәлгә ашыру. | | |
| 10. | Республикада күләмле проектларны гамәлгә ашыру инфраструктураны алдан үстерүне таләп итә. Россия Федерациясе Хөкүмәте, шәхсән Дмитрий Анатольевич Медведев ярдәме белән Чаллы шәһәрендә киләсе унъеллыкка илебез икътисадының үсеш ноктасы итеп билгеләнгән "ИнноКам" территориаль-аерымланган инновация үзәге концепциясен гамәлгә ашыру кысаларында Чаллы шәһәрендә алдан үсеш территориясен булдыру турында карар кабул ителде.<br>Республикада төзелгән индустриаль мәйданчыклар челтәре үзенең нәтиҗәлелеген күрсәтте. Шулар арасында үзләренең унъеллыкларын билгеләп узган "Алабуга" махсус икътисадый зонасы һәм "Химград" технополисы, Европада иң эре "КИП "Мастер" индустриаль паркы, ике IT-парк мәйданчыгы. | 10.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Бюджет, салымнар һәм финанс комитетының күчмә утырышында "Махсус икътисадый зоналар резидентларына салым ташламалары бирүнең нәтиҗәлелеге турында" мәсьәләне карау. | 2017 елның IV кварталы | Л.А. Якунин |
| 11. | ...җирләрнең категорияләрен үзгәртүгә бәйле вәзгыять борчу тудыра. Соңгы 10 елда гына да уннарча мең гектар авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр Казан һәм Чаллы шәһәрләре тирәсендә урнашкан торак пунктлар җирләренә кертелде. | 11.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты һәм "Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү" Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә | 2017 елның марты | Р.Т. Борһанов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Массакүләм күчерүләр, бер яктан, авыл хуҗалыгы җирләренең шактый кимүенә, икенче яктан, шәхси торак төзелеше өчен күчерелгән кишәрлекләрнең инженерлык инфраструктурасыннан һәм социаль инфраструктурадан башка, күп очракта кыйммәт бәягә, сатылуына китерде.<br>Муниципаль берәмлекләр башлыклары, республика Хөкүмәте үз карарларын бик нык уйлап кабул итәргә, башка категориягә күчерелеп тә буш ята торган җирләргә карата мөмкин булган барлык ысулларны – салым салудан башлап, җирне тартып алуга кадәр кулланып, катгый мөнәсәбәттә булырга тиеш.<br>Ассызыклыйм – җир буш ятмаска тиеш! | ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында “Торак төзелеше бүлеп бирелгән җир кишәрлекләрен инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү турында” мәсьәләне карау.<br><br>11.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында “Җир законнары нигезләмәләрен җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру өлешендә гамәлгә ашыру турында” мәсьәләне карау. | <br><br><br><br><br><br><br><br>2017 елның сентябре | <br><br><br><br><br><br><br><br>Т.Г. Һадиев |
| 12. | Җир белән эш иткәндә белемсезлек, битарафлык, шулай ук явыз ниятә файдаланулар булырга тиеш түгел. Барлык процедуралар тулысынча ачык һәм аңлаешлы булырга тиеш.<br>Өлешләп төзү мәсьәләсе элеккечә кискен тора. Кулланылган чаралар 5 проблемалы йортны төзеп бетерергә ярдәм итте. Меңгә якын өлешле торак төзүдә катнашучы, ниһаять, тораклы булды. Чаллы шәһәрендә алга китү сизелә.<br>Казан шәһәре җитәкчеләре әлеге юнәлештә эшләүне арттырырга тиеш. | 12.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында һәм җирле үзидарә органнарында норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертиза уздыру турында” контроль мәсьәләне карау. | 2017 елның мае | Ш.Ш. Яһудин |
| 13. | Республика алдында торган бурычларны хәл итүгә ирешү инновацияле икътисад булдырудан башка мөмкин түгел. | 13.1. “Республика оешмаларының һәм индивидуаль эшкуарларының азык-төлек продукциясенең сыйфаты һәм | 2017 елның октябре | Р.Т. Борһанов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Әлеге эшкә, инновацияләр кертү нәтиҗәләре буенча кызыксындыру системасын булдырып, үзебезнең предприятиеләрне күбрәк җәлеп итәргә кирәк. Республиканың Дәүләт Советы инновация өлкәсенә кагылышлы законнар белән тәэмин итәргә тиеш. | куркынычсызлыгы таләпләренә туры килә торган, шул исәптән "Милли сәүдә маркасы" билгесе белән тамгаланган азык-төлек продукциясен базарга чыгару шартлары турында" темасына "түгәрәк өстәл" уздыру.<br><br>13.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында "Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге өлкәсендә законнарны камилләштерү" мәсьәләсен карау. | <br><br><br><br><br><br>2016 елның ноябре | <br><br><br><br><br><br>Р.Т. Борһанов |
| 14. | Өстенлекләрнең берсе булып кече һәм урта бизнеска ярдәм итү тора. Без административ киртәләрне киметүгә юнәлдерелгән планлы эш алып барабыз. Моңа республиканың 5 эре шәһәрендә ачылган яңа күпфункцияле үзәкләр эше ярдәм итә. Мондый практиканы башка муниципаль берәмлекләргә дә җәелдерергә кирәк.<br>Реаль секторда кече һәм урта бизнесны үстерүдә муниципаль сәнгать мәйданчыкларының әһәмияте зур. Бүген республикада шундый 52 мәйданчык бар. 2020 елга кадәр аларның санын бер йөзгә җиткерү бурычы тора. | 14.1. "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең сәнәгать мәйданчыклары проблемалары һәм аларның үсеш перспективалары" темасына "түгәрәк өстәл" уздыру. | 2017 елның апреле | Р.Т. Борһанов |
| 15. | Республикада авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы гамәлгә ашырыла. Бу уңай нәтиҗәләр бирә. Агымдагы елның 8 ае йомгаклары буенча авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 7% ка арткан. | 15.1. Түбәндәге мәсьәләләрне карау:<br>1)"2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу" дәүләт программасын 2016 елда үтәү йомгаклары һәм 2017 елның I кварталына планнар | 2017 елның гыйнвары | Т.Г. Һадиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген арттыру эшен дәвам итәргә кирәк. Бу күрсәткечләр республика буенча төрлечә. Мәсәлән, бер үк төрле һава торышы шартларында, агро-технологик чараларны дөрес куллану исәбенә Әтнә районында җыелган уңыш, Ютазы районы белән чагыштырганда, гектарына 11 центнерга артыграк, Актаныш районында 44 мең гектар мәйданда җыелган бөртеклеләр уңышы Әлмәт районында шундый ук мәйданда җыелган уңышка караганда 30 %ка күбрәк булды.<br>Бу шулай ук хуҗалыкларга да кагыла. Артта калган хуҗалыкларның үсешенә уңай тәҗрибәдән файдаланып этәргеч бирергә кирәк. | турында";<br>2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты һәм "2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу" дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында "Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында". | | |
| 16. | Товар җитештерүчеләребез һәрвакыт үсештә булырга һәм республикадан читтә дә конкурент булырга тиеш. Моңа гамәлгә кергән "Милли сәүдә маркасы" проекты да ярдәмгә килер. Безнең брендның киң танылуы һәм кулланучылар тарафыннан продукциянең югары сыйфат күрсәткече буларак кабул ителүе мөһим.<br>Авыл хуҗалыгы министрлыгы, әйдәп баручы агрофирмалар һәм сәүдә челтәрләре белән берлектә Милли сәүдә маркасы продукциясенең таралу даирәсен киңәйтүне тәэмин итәргә тиеш.<br>Без авыл хуҗалыгы чималын эшкәртү темасы турында берничә тапкыр фикер алыштык. Республикада азык-төлек | 16.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында "Татарстан Республикасында азык-төлек продукциясенең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча аерым чаралар турында" Татарстан Республикасы Законын, "Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында" Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законны гамәлгә ашыру турында" мәсьәләне карау. | 2017 елның апреле | Т.Г. Һадиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кластеры булдырылды, яңа эшкәртү производстволары ачыла. Шулай булса да Татарстанга елына 70 млрд. сумнан артык продукция кертү дәвам итә. Әлеге резервтан республиканың товар җитештерүчеләре һәм эшкәртүчеләре файдаланырга тиеш. | | | |
| 17. | Авыл – республиканың нигезе, аның таяныр ноктасы. Телне, динне, мәдәниятне һәм милли рухны саклауга ул зур өлеш кертә. Безнең программаларның күбесе авыл үсешенә юнәлтелгән. Без алга таба да бу эшне дәвам итәчәкбез. | 17.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында “Авылда мәдәният оешмалары челтәре эшчәнлеге турында” мәсьәләне карау. | 2017 елның декабре | Р.И. Вәлиев |
| 18. | Бакчачылык һәм дача хуҗалыгы өлкәсендә шактый сораулар җыелды.<br>Республикада меңгә якын бакчачылык ширкәте бар. Татарстанлыларның чиреге диярлек җәйне бакча кишәрлекләрендә үткәрә. Хакимият органнарының бурычы – бакчачылар өчен уңай шартлар тудыру. Сүз иң гади әйберләр турында бара: бакчаларны су, электр, керү-чыгу юллары белән тәэмин итү, чүпне чыгаруны оештыру.<br>Республика Хөкүмәте әлеге мәсьәләләр өстендә эшли инде. Киләсе елдан без бу өлкәдә өчьеллык программаны гамәлгә ашыра башлыйбыз.<br>Моннан тыш, кайбер эшләр, республика бюджетыннан бирелгән субсидияләр белән беррәттән, гражданнарның үзләреннән җыелган акча исәбенә хәл ителергә тиеш. | 18.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты утырышында “Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренә ярдәм итү программасын гамәлгә ашыруга 2017 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган чаралар турында” контроль мәсьәләсен карау.<br><br>18.2. Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләренә ярдәм итү программасын камилләштерү һәм аны гамәлгә ашыру тәкъдимнәрен эшләү.<br><br>18.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында “Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек | 2016 елның IV кварталы<br><br>2017 елның II кварталы<br><br>2017 елның марты | Л.А. Якунин<br><br>Х.Г. Миргалимов<br><br>Т.Г. Һадиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләрен үстерүгә һәм аларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар турында" мәсьәләне карау. | | |
| 19. | Яңа технологияләрне күпләп кертү, яңа һөнәрләр һәм белгечлекләр барлыкка килү белем бирү, бигрәк тә һөнәри белем бирү, системасын үз вакытында камилләштерүне таләп итә. Барлык белем бирү программалары икътисад таләпләрен истә тотып төзелергә тиеш. Эш бирүчеләр аларны әзерләүдә актив катнашырга, көтеп тору белән шөгыльләнмәскә тиеш.<br>Квалификацияле кадрлар әзерләү бурычын белем бирү оешмалары һәм предприятиеләр катнашында хәл итүгә ресурс үзәкләре челтәрен булдыру ярдәм итә. Быел 20 үзәк булса, якындагы киләчәктә аларның санын 30га җиткерү бурычы тора.<br>Конкурентлыкка сәләтлелекне белем бирү эшчәнлегенә дөньякүләм стандартлар кертү өлешендә методикага нигезләнгән һәм системалы эш тәэмин итәчәк. Бу WorldSkills хәрәкәтенә дә кагыла, без дөньякүләм дәрәҗәләргә ирешмәсәк тә, Россия субъектлары арасында лидерлар рәтендә торабыз.<br>Моннан тыш, остазлык институтын үстерүгә игътибар итәргә кирәк. | 19.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында "Һөнәри белем бирү системасында педагогик кадрлар әзерләү турында" мәсьәләне карау. | 2017 елның апреле | Р.И. Вәлиев |
| 20. | Гомуми белем бирү сыйфатына аерым тукталасым килә. Безнең югары дәрәҗәдәге олимпиадаларда катнашучыларны әзерләү тәҗрибәбез | 20.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Татарстан Республикасында белем бирүне үстерү программасын гамәлгә ашыру барышы | 2016 елның декабре<br>2017 елның декабре | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бар. Бу – укучының, укытучының һәм ата-аналарның тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Барлык мәктәпләребездә укучыларны белем сыйфатының гомуми дәрәҗәсе белән тәэмин итәргә, педагогик практикада иң алдынгы инновацияләр кертүне дәвам итәргә, уку-укыту процессын оештыруга иҗади яктан килергә кирәк.<br>Мәгариф оешмаларның республика рейтингында көчле һәм көчсезрәк мәктәпләр арасындагы аерманы, һичшиксез, кыскартырга кирәк. Мәсәлән, районнар буенча БДИ уртача баллары аермасы математикадан 20 балл тәшкил итә, югары балларның аермасы – 21 процент. Нәтиҗәләрнең мондый аерымлыгын бетерергә кирәк. | турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады. | | |
| 21. | Тел сәясәтенә Татарстанда зур әһәмият бирелә. Рус телен укытуны камилләштерүгә без зур игътибар биреп килдек һәм бирәчәкбез. Республика укучылары әлеге фән буенча БДИда югары нәтиҗәләргә ирешәләр.<br>Моннан тыш, замана чит телләрне, бигрәк тә инглиз телен белү дәрәҗәсен камилләштерүне таләп итә.<br>Шул ук вакытта безнең бәхәссез өстенлекләребезнең берсе булып милли мәгариф мәсьәләсе тора. Агымдагы елда 2030 елга кадәр Милли мәгарифне үстерү концепциясе кабул ителде. Мәгариф министрлыгына Концепцияне гамәлгә ашыру буенча “юл картасы” әзерләргә һәм расларга кирәк. Татарстан | 21.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында “Һөнәри белем бирү системасында педагогик кадрлар әзерләү турында” мәсьәләне карау<br>*(ресурс үзәге – “Г.Тукай исемендәге Арча педагогия колледжы” дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында).* | 2017 елның апреле | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | туган йортына әверелгән һәр халыкның телен саклау һәм үстерү өстендә эшләргә тиешбез.<br>Тел – милләтнең төп билгесе. Туган телне саклау һәм аны үстерү – безнең уртак бурыч. Татар телен укыту һәм укытучылар әзерләү дәрәҗәсен күтәрергә кирәк. Татар теле дәресләре балалар өчен кызыклы булуы мөһим. | | | |
| 22. | Республикада талантлар белән эшләүгә зур игътибар бирелә, программалар белән тәэмин итү чаралары гамәлгә ашырыла – талантлар белән идарә итү стратегиясе, “Алгарыш”, махсус стипендияләр, төрле форумнар һәм фестивальләр: Созвездие – Йолдызлык, “Студентлар язы”, “Сәләт”, “Кадрлар резервы”, “Президент академиясенең җәйге кампусы” проектлары һ.б. оештырыла, яшьләр инновация иҗат үзәкләре булдырылды.<br>Чаллы шәһәрендә IT-парк базасында КАМАЗ ярдәмендә эшли торган “Кванториум” балалар технопаркы мәйданчыгы яшь талантлар өчен бик кызыклы.<br>Агымдагы елның ахырына кадәр Түбән Камада һәм Әлмәттә тагын ике мәйданчык ачылачак. Балалар технопарклары үсеп килүче буынның республикабызда кирәкле яңа һөнәрләрне өйрәнүнең башлангычы булып торырга тиеш.<br>Гомумән алганда, балалардагы иҗади, гамәли характердагы талантны | 22.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында “2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән идарә итү стратегиясе” дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышы турында”гы мәсьәләне карау<br>*(В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университетында, “Зарница” балалар фәнни-күңел ачу үзәгендә булу).* | 2016 елның сентябре (үтәлде) | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ачыклау – барлык мәктәпләребезнең һәм өстәмә белем бирү учреждениеләренең беренче урында торучы бурычы. Һәр бала талантлы. Иң мөһиме – баланың талантын вакытында ачыклау һәм аны тормышка ашыру өчен шартлар тудыру. | | | |
| 23. | Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә гражданнарның күп санлы мөрәҗәгатьләре күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакы һәм сыйфатына кагыла. Барыннан да элек өлкәнең үтә күренмәлелеген арттырырга кирәк.<br>Бурыч – идарә итүче компанияләрне һәм барлык хезмәт күрсәтүләр, энергия ресурслары белән тәэмин итүчеләрне ТКХ системасының Дәүләт мәгълүмат системасына кертү. Бу акча әйләнешен контрольдә тотачак: кулланучы – идарәче компания – коммуналь оешма – энергия ресурслары белән тәэмин итүче.<br>Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләре сыйфатын арттыру, шулай ук хезмәт күрсәтү базарындагы конкуренция һәм тикшереп торучы органнар тарафыннан тиешле күзәтчелек исәбенә дә гамәлгә ашырылырга тиеш. | 23.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм “Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында “Лицензия контроленең үтемлелеген арттыру нәтиҗәләре һәм чаралары турында” мәсьәләне карау.<br>23.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе утырышында “Кулланучы – идарәче компания – катлаулы мөнәсәбәтләр” мәсьәләсен карау. | 2017 елның сентябре<br><br>2017 елның I кварталы | Р.Т. Борһанов<br><br>Х.Г. Миргалимов |
| 24. | Республика торак пунктларында инженерлык челтәрләре һәм су җибәрү системалары корылмаларының торышы, шулай ук эчә торган суның сыйфаты борчылу тудырмый калмый.<br>Су җыю җайланмаларында заманча технологияләр кертү һәм суны чистартуга чыгымнарны киметү һәм, суның икенче тапкыр пычрануын да истә | 24.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында түбәндәге мәсьәләләрне карау:<br>1) “Халыкны сыйфатлы эчә торган су белән тәэмин итү өлешендә законнар үтәлеше турында”;<br>2) “Татарстан Республикасында су саклау | 2017 елның июне | Т.Г. Һадиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тотып, балалар бакчаларында, мәктәпләрдә, хастаханәләрдә һәм торак йортларда су чистартуны өстәмә җайланмалар белән тәэмин итү мәсьәләсе өстендә эшләргә кирәк.<br>Шулай ук муниципаль берәмлекләр башлыкларының су белән тәэмин итү һәм су җибәрү объектларына инвентаризация үткәрүне дәвам итүләрен һәм Төзелеш министрлыгы белән берлектә аларны норматив торышка китерү өчен инвестиция чыгымнарының бәясе күрсәтелгән тәкъдимнәр әзерләүләрен сорыйм.<br>Республика Хөкүмәте тиешле инженерлык структурасын, компанияләрнең үз инвестиция программалары исәбенә һәм республика бюджеты исәбенә, яңадан торгызу өчен алдан акчалар карарга тиеш. | зоналарының экологик торышы турында”. | | |
| 25. | Агымдагы елда “Халык контроле” системасының “Поликлиникалар һәм хастаханәләр” категориясендә мөрәҗәгатьләр саны дүрттән бергә артты. Бу сәламәтлек саклауның халык күбрәк мөрәҗәгать итә торган беренче звеносы эшен камилләштерү кирәклеге турында сөйли. | 25.1. Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең күчмә утырышында “Чаллы шәһәре халкына беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне оештыру турында” мәсьәләне карау<br>*(Чаллы шәһәрендә “дуслык поликлиникасы”нда булу).* | 2016 елның ноябре | С.М. Захарова |
| 26. | Медицина иминияте оешмаларының ресурсларыннан киңрәк файдаланырга кирәк. | 26.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының һәм Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны | 2017 елның марты | С.М. Захарова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең күчмә утырышында “Иминият компанияләре тарафыннан пациентларның хокукларын яклау турында”гы мәсьәләне карау. | | |
| 27. | Үз-үзен тәэмин итү мөмкинлеген югалтучылар өчен тормыш итүнең уңай шартларын булдыру буенча, шулай ук гражданнарның икътисадый бөтенлеген һәм актив гомерен арттыру өчен шартлар тудыру эшен камилләштерү зарур. | 27.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында “2025 елга кадәр Россия Федерациясендә өлкән буын гражданнары мәнфәгатьләрендә чаралар стратегиясен Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру турында”гы мәсьәләне карау. | 2017 елның июне | С.М. Захарова |
| 28. | Сәламәтлекне саклау культурасы күнекмәләрен булдыра торган профилактик чараларга һәм гражданнарның үз сәламәтлекләрен саклауга һәм кайгыртуга мотивациясен арттыруга басым ясарга кирәк. | 28.1. “Гражданнарның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга мотивация булдыру турында” темасына “түгәрәк өстәл” уздыру. | 2017 елның сентябре | С.М. Захарова |
| 29. | Республика алдында торган бурычларның күплеге хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә махсус таләпләр куя.<br>Кабул ителә торган идарәчел карарларның сыйфатын арттыру, белгечләрне яңадан әзерләүне һәм кадрлар резервы белән эшләүне камилләштерү, проект идарәсен киңәйтү, алдынгы тәҗрибәне активрак файдалану һәм барлык дәрәҗәдәге хакимият органнары эшчәнлегенең ачыклыгын арттыру кирәк. | 29.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең квалификациясен планлы рәвештә күтәрү.<br><br>29.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең “Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре” исеменә еллык Республика конкурсында катнашулары. | ел дәвамында<br><br>ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 30. | | 30.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы фракцияләрнең 2017 елга Татарстан Республикасы Президентының | ел дәвамында | Ю.З. Камалтынов, Х.Г. Миргалимов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы нигезләмәләрне гамәлгә ашырулары. | | |